# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Татар Димскәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Суык Чишмә авылы торак пункты**

2024 елның 06 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Татар Димскәе авыл җирлегенә керүче Суык Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Татар Димскәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Суык Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, күпбалалы гаиләләрдән һәм махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелгагн акчаларны торак пункт территориясен төзекләндерүгә (Суык Чишмә, спил Авылының төп урамы территориясен чистартуга һәм агачлар һәм куаклар чыгаруга) тотарга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**Татар Димскәе авыл җирлеге башлыгы Л. Ә. Хәбирова**